ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
« ИСКЕ ЧАЛЛЫ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ»

# ХӘТЕР МӘҢГЕ САКЛАР




ПРОЕКТ ЭШЕ

Проект эшенең җитәкчесе:
Хазипова Фаузия Фасиховна
I квалификацион категорияле
башлангыч сыйныф укытучысы

## Проектның проблемасы:

**Һәр укучы бала өчен туган җире, Ватаны, якыннары беренче урында булырга тиеш;**
**Һәр кеше туган илен саклауга, аны үстерүгә үзеннән өлеш кертергә тиеш.**

## Проектның максаты:

**1. Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның фронтта һәм тылда күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы үрнәкләре белән яшь буынны таныштыру;**
**2.Буыннар арасындагы бәйләнешне ныгыту, намуслы хезмәт белән көн күргән сугыш һәм тыл ветераннарына, әби-бабайларга карата олы хөрмәт хисе тәрбияләү;**
**3. Гадел, тату, эшчән, игелекле булырга омтылыш уяту;**
**4. Эзләнү-тикшеренү эше аша балаларның Бөек Ватан сугышы турындагы белемнәрен тагын да тирәнәйтү.**
**5.Белемгә омтылучан, мөстәкыйль, физик һәм психик сәламәт, конкурент буларга сәләтле шәхес тәрбияләү.**

.

## Проектның бурычлары:

**1. Ватанга карата хөрмәт, горурлык, ярату хисе тәрбияләү**

**2.Сугыш ветераннарына, әби-бабаларыбызга карата ихтирам хисе, игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү.**

**3. Укучыларның иҗади эшчәнлеген, мөстәкыйль фикерләвен үстерү.**

**4. Эшне оештыру һәм аны башкару сәләтен тәрбияләү.**

**5. Көндәлек матбугат, өйрәнелгән чыганаклар белән эшләү күнекмәләре булдыру.**

## Проектның актуальлеге:

Әлеге проект бүгенге көндә бик **актуаль**,чөнки туган илнең тарихы белән бүгенгесе көндә яшәешен белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган иленең тарихын һәм бүгенгесен өйрәнергә, шуның аша киләчәккә якынаерга тиеш. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала, анда милли аң ышанычлы формалаша.

**Эш төркеме:** башлангыч сыйныф укучылары.

**Үткәрелү вакыты:** сентябрь-май айлары.




**Проектның төре**: иҗади, эзләнү - тикшеренү

Проект катнашучыларның социаль кызыксынуларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән.

**Дәвамлылыгы** : 9 ай (сентябрь- май).

**Проектның функцияләре**: күп функцияле, иҗади, мәгълүмати, тикшеренү.

**Проектның катнашучылары**: башлангыч сыйныф укучылары.

Проект **3 бүлекне** үз эченә ала.

**Проектның бүлекләре:**

I бүлек. Ватанга килгән афәт

1. Сугыш хатирәләрен барлап

2.Илем күгендә сугыш (мәгълүмат туплау)

II бүлек. Туган якта сугыш җилләре

1.Яу кырында дан яулап...

2.Алар безнең сафта

III бүлек. Хәтер мәңге саклар

1. Һәйкәлләргә килик!

# С.М.Лисенков исемендәге туган якны өйрәнү музеенда














# СУГЫШ ХАТИРӘЛӘРЕН БАРЛАП



*Җиңү көне!*
*Халык бәйрәм итә.*
*Яз төренгән янар комачка.*
*Җир чәчәкләр тезгән күкрәгенә,*
*Йөз балкытып карый кояш та.*

- **1941 нче елның 22 нче июне һәм 1945 нче елның 9 нчы мае.**
- **1418 көн һәм төн буена фидакарь көрәш сәхифәсе.**
- **Күпмилләтле илебез фашизмга каршы канкойгыч сугышта җиңеп чыга.**






**1941 ел, 22 июнь**

***Радио шомлы хәбәр китерә. Фашистлар Германиясе Советлар иленә вәхшиләрчә һөҗүм ясый. Ватан сугышы башлана. Шул көнне үк завод-фабрикаларда, мәктәп-институтларда, колхозларда, гомумән бөтен җирдә митинглар үткәрелә. Эшчеләр, колхозчылар, студентлар, укучылар, врачлар, барлык кеше сугышка каршы булуларын белдерәләр.***









***Фашист окупантлары илебезнең 1710 шәһәрен, 70 меңнән артык авылын яндырдылар һәм җимерделәр. Совет халкы дошманны җиңү өчен барысын да эшләде. Фронттагылар соңгы сулышларына кадәр көрәштеләр.***



***Ә авылда. .. Авылда тормыш карт-коры, хатын-кыз, бала-чага кулына күчте. Авылдагы тормыш икенче фронтка әйләнде.***

***Солдат хатыннар! Аларның тормышлары михнәтле, тамаклары ачлы-туклы, күңелләре тулы сагыну иде. Эшенә, ачлыгына  түзәр идең, хатыннарны тол, бала-чагаларны ятим итеп авылга туктаусыз кара печатьле кәгазьләр агылды.***







НКО—СССР
Молотовский
Районный Военный
Комиссариат
Ставропольского края
по первой части
8 апреля 1945 г.
№ Вх-4/6-п.
с Молотовское

Извещение

Ваш брат красноармеец
(муж, сын, брат, военное звание)
Побединцев Алексей Романо...
Уроженец с. Привольное Став-
(область, р-н деревня село)
ропольский край Молотовск...

В бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество погиб 27.2...
Похоронен ... дер. Гросс Петфедор...
... кладбище, ... Германия.

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР)

Районный военный комиссар
Нач. 1-й части ст. л-т

***Бөек Ватан сугышы чорында зурлар белән беррәттән балалар да тиңдәшсез батырлыклар күрсәттеләр. Партизан отрядларында көрәштеләр, госпитальдә яралы сугышчыларга булыштылар, китаплар, хатлар укыдылар.***









**Халкыбыз Бөек Җиңүгә ышаныч белән яшәде һәм көрәште**

Никто не забыт, ничто не забыто



***Сугыш инде күптән бетте... Окоплар инде җир белән тигезләнделәр, аларны яшел чирәм каплап китте, фронт юллары урынында яңа шәһәрләр һәм авыллар барлыкка килде, блиндажлар чәчәкләр белән капланды. Тик сугыш хатирәләре онытылмыйлар.***

***Сугыш тавышлары күптән тынды,***
***Төзәлделәр җирнең яралары,***
***Әтиләрнең окопларын сөреп,***
***Иген чәчә хәзер балалары.***
***Сугыш тавышлары тынды, ләкин***
***Күңелләрдә шомы яши һаман.***
***Сугыш агачларын аударсак та,***
***Кайлардадыр әле тамыры калган***



***Җиңү килде җирне нурга күмеп,***
***Шатлык белән күзне чылатып.***
***Килде ул көн горур күкрәкләрдә***
***Орден-медальләрне чыңлатып.***





# Яу кырында дан яулап...




Фашизмга каршы көрәштә Әлки ягының 9 мең кешесе катнашкан,шулардан 5 меңе генә туган якларына әйләнеп кайта алган.




**Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булдылар**

1. Шагвалеев Галямзян Нургаязович
2. Исхаков Зинатулла Генатулаевич
3. Крайнов Степан Матвеевич
4. Чулков Алексей Петрович
5. Филиппов Гордей Иванович
6. Афанасьев Кузьма Кириллович



# Кайманов Никита Фадеевич

**Беренче Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган**

**СӘГЫЙРОВ**
**КАШШАФ СӘГЫЙРЬ улы**
**22.05.1923 -2016**
**Бөек Ватан сугышы ветераны**



**Медальләре:**
“За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941- 1945 гг.”
“ За отвагу”
“20 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“25 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“30 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“40 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“50 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
медаль Жукова
“50 лет Вооруженных сил СССР”
“60 лет Вооруженных сил СССР”
“70 лет Вооруженных сил СССР”




ХАЙРЕТДИНОВ
ГАРӘФЕТДИН
ХАЙРЕТДИН улы
(1913 - 1994 )

Бөек Ватан сугышы ветераны

“За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941- 1945 гг.”
“20 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“25 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“30 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“40 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 гг.”
“50 лет Вооруженных сил СССР”
“60 лет Вооруженных сил СССР”

# Гайсин Сәлим



Гайсин Сәлим 1910 нчы елның 23 мартында Иске Чаллы авылында туа. Сугышка кадәр комбайнер булып эшли. 1942 елда аны сугышка алалар. Сәлим абый сугыш юлын Иске Рус шәһәреннән башлый. Иң авыр вакыйга чик буенда “тел” алу була. “1943 елда өч солдат һәм капитан чик буена бардык. Безнең килгәнне ике тапкыр сизделәр, шуннан соң 2 км кардан шуышып штабка кайттык. Өченче көнне тагын чиккә киттек. Блиндаҗдагы сакчыны кочаклап алдым, икенчебез аның авызына чүпрәк тутырды. Немецны капчыкка салып тавышсыз гына штабка алып кайттык. Шуның өчен “Кызыл йолдыз” ордены белән бүләкләндем. Сугыштан соң Сәлим абый трактор бригадиры булып эшли.

# Хайдаров Нурлыхак



Хайдаров Нурлыхак 1923 елның 15 сентяберендә туган. 1938 елда 7 класс белем алып Урал алюмин заводына эшкә китә. 1941 елда авылга кайта һәм колхозда эшли башлый. 1942 елның җәендә сугышка китә. Владимир шәһәрендә миномент училиәасын тәмамлап кече сержант дәрәҗәсен алып фронтка китә. 55 нче гвардия полкында һөҗүм вакытында яралана. Ржев шәһәре янында 9 ай госпитальдә дәвалана һәм терелеп Красноярск шәһәре ВОХР частенә җибәрелә.

Иң авыр сугыш вакыйгасы “Яраланганнан соң сугыш кырыннан чыга алмыйча ике атна буена яралы хәлдә сугыш кырында яттым. Ике атна узганнан соң гына мине сугыш кырыннан алып чыгып Волокосламский шәһәрендә миңа перевязка ясадылар.” Сугышны бетергәннән соң да Нурлыхак абый әле тагын бер ел хезмәтен дәвам итә. 1946 елда туган авылына кайта. Шул вакыттан бирле ул 26 ел Иске Чаллы авылы элемтә бүлеге мөдире булып эшләде. 1972 елны авыл Советы председателе итеп сайлана. Бу вазыйфаны ул 11 ел буена җитәкли һәм 1983 елда лаеклы ялга чыга. 1989 елда үлә.

# Базиров Солтан

Базиров Солтан 1916 елның 9 маенда Иске Чаллы авылында туган. Сугышка кадәр ул күп еллар буе Яңа Чаллы мәктәбендә укытучы булып эшләгән. Аннан соң район җир бүлеге секретаре булып эшләгән. 1941 елның июлендә сугышка киткән. 963 нче укчы девизиясендә взвод командиры булып хезмәт иткән. “Медаль за Отвагу», «За услуги» һәм башка күп медальләр белән бүләкләнгән. Иң истәлекле вакыйга: “1941 елның 20 сентяберендә Волхов фронтында Ладага күлен һәм Петрозаводск , Медвежогорск шәһәрләрен алу өченсугышлар бара. Бу вакытта девизия бөтенләй юкка чыккан вакыт иде. Бу фронтта күпләп фин халкы катнашты.”

Сугыштан соң Солтан абый 1946 елның декаберендә туган ягына кайта. Авыл советы секретаре, бригадир, умартачы булып эшли.

# Мухаметшин Касым



Мухаметшин Касым Хафиз улы 1923 елда крестьяннар гаиләсендә туган. Сугышка кадәр ул төрле эштә колхозда эшләп йөри. Сугыш башлануның беренче көннәреннән үк туган илен яклар өчен яу кырына китә. Касым абый Украинский фронтта Жуковский җитәкчелегендә сугыш елларын үтә. Аның бик күп бүләкләре бар: “За отвагу”, “За взятие Кенеберга”, “За победу над Германией” һәм башкалар. Иң истәлекле вакыйга: “ Мин Львов шәһәре янында бер атна ач тордым.Пычрак, ыршытылган бәрәңге кабыклары ашап йөрдек. Әле ул бәрәңгеләрне дә алырга ярамый иде. Аларны төнлә генә, качып ала идек. Шул бәрәңгеләрне алган өчен иң каты җәза – үлем иде. Юынмыйча, ашамыйча шулай бер атна үтте. Күлмәк якалары пычраклыктан бетләп бетте. Бер атнадан соң разведчиклар килеп безнең чолганышны өзделәр һәм алар безне үлемнән коткардылар. Бу хәл Ворошиловград шәһәре янында булды.”

Сугыштан соң Касыйм абый Германиядә Дрезден шәһәрендә хезмәт иткән. 1949 елда авылына әйләнеп кайткан һәм комбайнер булып эшли башлаган. Аннан соң бригадир, тимерче булып эшләгән.

# Салахов Халим

Халим абый 1911 елның 22 нче апрелендә туган. Сугышка кадәр Бибай чаллы авылы колхозында председатель булып эшләгән. 1941 елның 23 июнендә сугышка киткән. Житомир шәһәреннән Днепр елгасына хәтле сугышкан. 23 нче сентяберендә окружениягә эләккән. Сугшның азаккы көннәренә чаклы чолганышта, пленда булган. 1945 елның 7 нояберендә туган ягына әйнәнеп каткан. Бик күп буләкләр иясе. Сугыштан соң Халим абый күп еллар колхозда төрле эшләрдә эшләгән. Аннан соң бригадир хезмәтендә эшен дәвам иткән. Соңыннан Халим абый төзүчеләр бригадыры булып эшләп. Шул вазыйфадан лаеклы ялга киткән.

# Гайнуллин Насрулла

**Гайнуллин Насрулла 1914 елның 5 январендә туа. Бик яшьли ятим кала. Нарсулла абыйны Иске Чаллының Мингали дигән карты уллыкка ала. Сугышка кадәр төрле эшләрдә эшли. 1941 елда ул сугышка китә.  Аның сугыш юлы Калинин шәһәреннән башлана.Аның иң авыр сугыш вакыйгасы Ленинградта була. Насрулла абый да шул сугышта катнаша. Алар чолганышта калалар. Хәлләре бик авыр була. “Көненә 200 гр.ипи белән яшәдек. Немец самолетлары Ленинградка безнең самолетларны кертмиләр. Сугышчылар зениткалардан бозга аталар, боз тишелә һәм шуннан алар балык тотып чи килеш балык ашыйлар. Бу авыр көннәр 93 көнгә сузыла.” Насрулла абый иптәшләре белән Ленинградны 1942 елның июль аеннан 1943 елның мартына кадәр саклыйлар. Шуннан соң алар немецларны Эстониягә, ә аннан соң инде Латвиягә чигендерәләр. 1945 елда Насрулла абый туган авылына кайта. Сугыштан соң 18 ел көтү көтә, ә аннан соң 4 ел завферма булып эшли.**

# Гарипов Харис

Гарипов Харис 1905 елда Иске Чаллы авылында туган. Сугышка кадәр төрле эшләрдә эшләгән. Сугышның беренче көннәрендә ук ул сугышка алына. Харис абый күп бүләкләр иясе. Сугыш дәвамында Харис абый немецларга пленга эләккән һәм бик озак вакыт тоткынлыкта булган. Пленнан азат ителгәннән соң Италиядә партизаннар отрядында сугыша. Ленинградны яңадан төзү эшләрендә катнаша.

Иң истәлекле вакыйга: Харис абый пленда чакта алар янына бер итальян солдаты килә һәм аларны партизанлыкка алып китә. Бу солдат итальян партизаннарының командиры була. Беркөнне болар янына граждан киемнәре кигән кеше килә. Алар үзләрен пленнан качкан русслар дип белдерәләр. Ләкин командир аларга су һәм киемнәр  каян алдыгыз, сез әсирләр түгел диеп аларны атып үтерергә боера.алар русс солдатлары булалар. Бу хәл Беломорканалда була.

Сугыштан соң Харис абый озак еллар буе бригадир хезмәтен башкара.

# Зарипов Гариф

**Зарипов Гариф абый Иске Чаллы авылында 1897 елда туа. Сугышка кадәр ул Мәскәү шәһәрендә электросеть учреждениясендә эшли. Үзенең сугыш юлын Гариф абый Мәскәү янында башлый. Ул “Добровольная часть защиты Родины” дигән батальонда хезмәт итә. Мәскәү астында I Украина фронтының маршал Жуков җитәкчелегендәге командада хезмәт итә. 1942 елда контузия ала. 1943 елга хәтле Ташкент госпиталендә ята. Ләкин аның ярасы белән яңадан сугышка керергә ярамый. Шуннан соң Ярославльдә “НКВД” участогында каравылчы булып эшли. 1947 елга хәтле Ивановада госпитальдә ята. Шул ук елны ул сугышчан частьтән чыгарыла. Сугыштан соң 1947 елда Иске Чаллыга кайта. Авылда төрле эшләрдә эшли.**

# Сабиров Харис

**Сабиров Харис абый 1908 нче елның30 нчы январендә Иске Чаллы авылында туган. Сугышка кадәр Казанның СК – 4 заводында автосваршик булып эшләгән. 1942 нче елны сугышка кергән. Сугыш дәвамында ике тапкыр яралана. Харис абый күп кенә медальләр һәм почет грамоталары иясе.**
**Сугыштан соң үзенең туган авылына кайткан һәм озак еллар буе көтү көткән.**

# Һәйкәлләргә килик!










# Бөек Ватан сугышы геройларына дан!









# ТЫНЫЧ ЯШИК!

Яшен уты катыш давыл үтте,
Күк күкрәтеп, ялкын яудырып.
Давыл тынды, Бөек Җиңү данын
Безнең кулыбызда калдырып.
Давыл үтте, безгә канат биреп,
Дошман явын җирдән себереп.
Давыл үткәч була торган ямьне
Безнең күңелебезгә иңдереп
Җир туй ясый бүген, җир шатлана,
Бүген Бөек Җиңү бәйрәме.
Җилфер-җилфер итә туган илнең
Данга манган кызыл байрагы
Давыл тынды, ләкин тәнебездә
Сызлап тора авыр яралар
Ут эченнән чыга белгән халык,
Яраларын гына дәвалар.
Җиңү данын илнең солдатлары
Гасырларга алып барырлар.
Туар еллар, безнең батырларны
Хөрмәт белән искә алырлар

